| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>Совет<br>Нижнеуратьминского сельского поселения<br>Нижнекамского муниципального района | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Түбән Кама муниципаль районы<br>Түбән Уратмаавыл җирлеге<br>Советы |
|---|---|
| 423567, Нижнекамский район,<br>с. Нижняя Уратьма ул. Центральная, 1 | 423567, Түбән Кама районы,<br>Түбән Уратма авылы, Үзәк урамы, 1 |

тел./факс (8555) 33-17-25, электронный адрес: Nizhneuratminskoe.sp@tatar.ru, сайт: www.nizhneuratminskoe-sp.ru


РЕШЕНИЕ КАРАР

19.03.2020 ел № 7

Түбән Уратма авыл җирлеге
Советының 2018 елның
19 декабрендәге 32 номерлы
«Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Түбән Уратма авыл җирлеге
территориясен төзекләндерү
кагыйдәләрен раслау турында»
карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Түбән Уратма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Түбән Уратма авыл җирлегенең тиешле санитар, янгынга каршы, эстетик торышын һәм анны алга таба төзекләндерүне тәэмин итү максатларында, Түбән Уратма авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Түбән Уратма авыл җирлеге Советының 2018 елның 19 декабрендәге 32 номерлы «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Уратма авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 статьяда

2.3-2.7, 2.16-2.18, 2.25, 2.26 пунктларын үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге Кагыйдәләрдә кулланыла торган һәм әлеге статьяда күрсәтелмәгән төшенчәләр РФ Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 – ФЗ номерлы Федераль законда һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан

Республикасының башка норматив хокукый актларында каралган мәгънәләрдә кулланыла».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Уратма авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.

Түбән Уратма авыл җирлеге
башлыгы: А.Р. Гарифуллин